ГЛАВА КУРАЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.25, с. Куралово,
422581

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КУРАЛОВО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 25 нче йорт, Куралово авылы,
422581

Тел.: (84379) 33-5-36, факс: (84379) 33-5-36.

29.10.2022 № 2

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлегенең Куралово авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлегенең Куралово авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юллау белән килешәсезме: - Куралово авылында гамәлдәге юлга вак таш җәю, дигән мәсьәлә белән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 849 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 445 кеше кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен җыенда 444 катнашучы тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен җыенда 1 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлегендә халык җыены булды дип, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга

2. «Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлегенең Куралово авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән билгеләнгән ташламалы гражданнардан тыш, һәр балигъ булган кешедән Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлегенең Куралово авылында 2023 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юллау белән килешәсезме: - Куралово авылында гамәлдәге юлга вак таш җәю, дигән сорау буенча карарны танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлегендә халык җыены нәтиҗәләрен Куралово авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Р.Е. Тарасов